**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О наделении органов местного самоуправления муниципальных образований в Республике Татарстан отдельными государственными полномочиями Республики Татарстан в области опеки и попечительства»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
18 марта 2019 года

## Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 20 марта 2008 года № 7-ЗРТ «О наделении органов местного самоуправления муниципальных образований в Республике Татарстан отдельными государственными полномочиями Республики Татарстан в области опеки и попечительства» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2008, № 3; 2010, № 7 (II часть); 2013, № 10) следующие изменения:

1) статью 1 изложить в следующей редакции:

«Статья 1. **Государственные полномочия Республики Татарстан в области опеки и попечительства, которыми наделяются органы местного самоуправления**

Органы местного самоуправления наделяются государственными полномочиями Республики Татарстан в области опеки и попечительства (далее – государственные полномочия):

1) по организации и осуществлению деятельности по опеке и попечительству в отношении несовершеннолетних лиц и лиц, признанных судом недееспособными или ограниченно дееспособными;

2) по назначению и выплате ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных под опеку (попечительство), в приемные семьи, и вознаграждения, причитающегося опекунам или попечителям, исполняющим свои обязанности возмездно.»;

2) в статье 4:

а) в части 1 слова «местным бюджетам» заменить словами «бюджетам муниципальных районов и городских округов»;

б) в части 2 слова «местным бюджетам» заменить словами «бюджетам муниципальных районов и городских округов»;

в) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. Расчет объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий по организации и осуществлению деятельности по опеке и попечительству в отношении несовершеннолетних лиц, производится в соответствии с Методикой расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления государственных полномочий по организации и осуществлению деятельности по опеке и попечительству в отношении несовершеннолетних лиц, согласно приложению 1 к настоящему Закону.»;

г) часть 4 изложить в следующей редакции:

«4. Расчет объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий по организации и осуществлению деятельности по опеке и попечительству в отношении лиц, признанных судом недееспособными или ограниченно дееспособными, производится в соответствии с Методикой расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления государственных полномочий по организации и осуществлению деятельности по опеке и попечительству в отношении лиц, признанных судом недееспособными или ограниченно дееспособными, согласно приложению 2 к настоящему Закону.»;

д) дополнить частью $4^1$ следующего содержания:

«$4^1$. Расчет объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий по назначению и выплате ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных под опеку (попечительство), в приемные семьи, и вознаграждения, причитающегося опекунам или попечителям, исполняющим свои обязанности возмездно, производится в соответствии с Методикой расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления государственных полномочий по назначению и выплате ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных под опеку (попечительство), в приемные семьи, и вознаграждения, причитающегося опекунам или попечителям, исполняющим свои обязанности возмездно, согласно приложению 3 к настоящему Закону.»;

3) абзац первый пункта 1 статьи 8 после слов «несовершеннолетних лиц» дополнить словами «, по назначению и выплате ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных под опеку (попечительство), в приемные семьи, и вознаграждения, причитающегося опекунам или попечителям, исполняющим свои обязанности возмездно,»;

4) в части 3 статьи 9 после слов «в отношении несовершеннолетних лиц» дополнить словами «, по назначению и выплате ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных под опеку (попечительство), в приемные семьи, и вознаграждения, причитающегося опекунам или попечителям, исполняющим свои обязанности возмездно,»;

5) в приложении 1:

а) наименование изложить в следующей редакции:

**«Методика**
**расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления государственных полномочий по организации и осуществлению деятельности по опеке и попечительству в отношении несовершеннолетних лиц**»;

б) абзац первый признать утратившим силу;

в) абзац второй изложить в следующей редакции:

«Настоящая Методика предназначена для расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий по организации и осуществлению деятельности по опеке и попечительству в отношении несовершеннолетних лиц.»;

г) абзац третий признать утратившим силу;

д) в пункте 1:

абзац первый изложить в следующей редакции:

«1. Объем субвенций, предоставляемых бюджету муниципального района, городского округа, рассчитывается по формуле:»;

абзац шестой изложить в следующей редакции:

«Нзi – начисления на выплаты по оплате труда, в процентах;»;

е) в абзаце первом пункта 2 слова «Заработная плата» заменить словами «Оплата труда»;

ж) в пункте 3:

абзац первый признать утратившим силу;

в абзаце втором слова «на заработную плату» заменить словами «на выплаты по оплате труда»;

абзац пятый изложить в следующей редакции:

«Нзi – начисления на выплаты по оплате труда, в процентах;»;

абзац седьмой изложить в следующей редакции:

«Снз – ставка начислений на выплаты по оплате труда.»;

б) приложение 2 изложить в следующей редакции:

«Приложение 2
к Закону Республики Татарстан
«О наделении органов местного
самоуправления муниципальных
образований в Республике
Татарстан отдельными
государственными полномочиями
Республики Татарстан в области
опеки и попечительства»

**Методика
расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления государственных полномочий по организации и осуществлению деятельности по опеке и попечительству в отношении лиц, признанных судом недееспособными или ограниченно дееспособными**

Настоящая Методика предназначена для расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий по организации и осуществлению деятельности по опеке и попечительству в отношении лиц, признанных судом недееспособными или ограниченно дееспособными.

Объем субвенций, предоставляемых бюджету муниципального района, городского округа, рассчитывается по формуле:

$$Si = Зi\ год \times (100\% + Снзi) \times Ki + Рм,$$

где:

Si – объем субвенции бюджету i-го муниципального образования для осуществления государственных полномочий по организации и осуществлению деятельности по опеке и попечительству в отношении лиц, признанных судом недееспособными или ограниченно дееспособными;

Зi год – расходы на оплату труда специалиста (в зависимости от группы по оплате труда) по опеке и попечительству i-го муниципального образования при осуществлении государственных полномочий на соответствующий год;

Снзi – ставка начислений на выплаты по оплате труда, в процентах;

Ki – количество должностей, определяемое из расчета одна должность на 100 тысяч человек взрослого населения муниципального образования, но не менее одной должности на каждый муниципальный район Республики Татарстан и не менее двух должностей на каждый городской округ Республики Татарстан;

Рм – расходы на материальное обеспечение специалистов по опеке и попечительству i-го муниципального образования, равные 10 процентам от расходов на оплату труда с начислениями на выплаты по оплате труда специалистов по опеке и попечительству.»;

7) дополнить приложением 3 следующего содержания:

«Приложение 3
к Закону Республики Татарстан
«О наделении органов местного
самоуправления муниципальных
образований в Республике
Татарстан отдельными
государственными полномочиями
Республики Татарстан в области
опеки и попечительства»

**Методика**
**расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления государственных полномочий по назначению и выплате ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных под опеку (попечительство), в приемные семьи, и вознаграждения, причитающегося опекунам или попечителям, исполняющим свои обязанности возмездно**

Настоящая Методика предназначена для расчета объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления государственных полномочий по назначению и выплате ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных под опеку (попечительство), в приемные семьи, и вознаграждения, причитающегося опекунам или попечителям, исполняющим свои обязанности возмездно.

1. Объем субвенций, предоставляемых бюджету муниципального района, городского округа, рассчитывается по формуле:

$$Si = Oci + Oei + Oвi,$$

где:

Si – объем субвенции бюджету i-го муниципального района, городского округа на осуществление ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных под опеку (попечительство), в приемные семьи, и выплаты вознаграждения, причитающегося опекунам или попечителям, исполняющим свои обязанности возмездно;

Осі – расходы і-го муниципального образования на осуществление ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных под опеку (попечительство);

Оеі – расходы і-го муниципального образования на осуществление ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных в приемные семьи;

Ові – расходы і-го муниципального образования на осуществление выплаты вознаграждения, причитающегося опекунам или попечителям, исполняющим свои обязанности возмездно.

2. Расходы і-го муниципального образования на осуществление ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных под опеку (попечительство), определяются по формуле:

$$Oci = ((P_1 \times K_{1i}) + (P_2 \times K_{2i})) \times 12,$$

где:

$P_1$ – размер ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, дошкольного возраста, переданных под опеку (попечительство), устанавливаемый Законом Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»;

$K_{1i}$ – среднегодовое количество детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, дошкольного возраста, переданных под опеку (попечительство), планируемое органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области образования, на основании данных органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов о фактической численности указанной категории детей за последние два завершенных финансовых года в і-м муниципальном образовании;

$P_2$ – размер ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, школьного возраста, переданных под опеку (попечительство), устанавливаемый Законом Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»;

$K_{2i}$ – среднегодовое количество детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, школьного возраста, переданных под опеку (попечительство), планируемое органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области образования, на основании данных органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов о фактической численности указанной категории детей за последние два завершенных финансовых года в і-м муниципальном образовании.

3. Расходы і-го муниципального образования на осуществление ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных в приемные семьи, определяются по формуле:

$$Oei = ((P_1 \times K_{1j}) + (P_2 \times K_{2j})) \times 12,$$

где:

$P_1$ – размер ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, дошкольного возраста, переданных в приемные семьи, устанавливаемый Законом Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»;

$K_{1j}$ – среднегодовое количество детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, дошкольного возраста, переданных в приемные семьи, планируемое органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области образования, на основании данных органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов о фактической численности указанной категории детей за последние два завершенных финансовых года в i-м муниципальном образовании;

$P_2$ – размер ежемесячной денежной выплаты на содержание детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, школьного возраста, переданных в приемные семьи, устанавливаемый Законом Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан»;

$K_{2j}$ – среднегодовое количество детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, школьного возраста, переданных в приемные семьи, планируемое органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области образования, на основании данных органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов о фактической численности указанной категории детей за последние два завершенных финансовых года в i-м муниципальном образовании.

4. Расходы i-го муниципального образования на осуществление выплаты вознаграждения, причитающегося опекунам или попечителям, исполняющим свои обязанности возмездно, определяются по формуле:

$$Овi = ((Р \times (К_{1j} + К_{2j} + К_{3j})) + (К_{4j} \times В) + (К_{5j} \times С)) \times (100\ \% + Н) \times 12,$$

где:

Р – размер вознаграждения, причитающегося опекунам или попечителям, исполняющим свои обязанности возмездно, в соответствии с частью 1 статьи $141^1$ Семейного кодекса Республики Татарстан;

$K_{1j}$ – среднегодовое количество детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, дошкольного возраста, переданных в приемные семьи, планируемое органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области образования, на основании данных органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов о фактической численности указанной категории детей за последние два завершенных финансовых года в i-м муниципальном образовании;

$K_{2j}$ – среднегодовое количество детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, школьного возраста, переданных в приемные семьи, планируемое органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области образования, на основании данных органов местного самоуправления

самоуправления муниципальных районов и городских округов о фактической численности указанной категории детей за последние два завершенных финансовых года в i-м муниципальном образовании;

$K_{3j}$ – среднегодовое количество детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, обучающихся в федеральных государственных образовательных организациях с дополнительными образовательными программами, направленными на проведение военной подготовки несовершеннолетних граждан, переданных в приемные семьи, планируемое органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области образования, на основании данных органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов о фактической численности указанной категории детей за последние два завершенных финансовых года в i-м муниципальном образовании;

$K_{4j}$ – среднегодовое количество детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, не достигших трехлетнего возраста, либо детей-инвалидов, либо детей, имеющих отклонения в психическом или физическом развитии, либо детей с девиантным поведением, относящихся к категории детей-сирот и детей, оставшихся без попечения родителей, переданных в приемные семьи, планируемое органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области образования, на основании данных органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов о фактической численности указанной категории детей за последние два завершенных финансовых года в i-м муниципальном образовании;

В – доплата в соответствии с частью 2 статьи $141^1$ Семейного кодекса Республики Татарстан;

$K_{5j}$ – среднегодовое плановое количество опекунов или попечителей, имеющих педагогическое или медицинское образование, планируемое в i-м муниципальном образовании органом исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченным в области образования, на основании данных органов местного самоуправления муниципальных районов и городских округов;

С – доплата в соответствии с частью 3 статьи $141^1$ Семейного кодекса Республики Татарстан;

Н – ставка начислений на выплаты по оплате труда, в процентах.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу с 1 апреля 2019 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
19 марта 2019 года
№ 21-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 18 мартында
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 3; 2010, № 7 (II өлеш); 2013, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. **Җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә бирелә торган Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләре**

Җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә түбәндәге дәүләт вәкаләтләре (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) бирелә:

1) балигъ булмаган затларга һәм суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча;

2) опекага (попечительлеккә) тапшырылган, тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләүне һәм үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләүне билгеләү һәм түләү буенча.»;

2) 4 статьяда:

а) 1 өлештә «җирле бюджетларга» сүзләрен «муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «җирле бюджетларга» сүзләрен «муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару, әлеге Законга 1 нче кушымтага таянып, Балигъ булмаган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару методикасы нигезендә башкарыла.»;

г) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җирле үзидарә органнары тарафыннан суд хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип таныган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару, әлеге Законга 2 нче кушымтага таянып, Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару методикасы нигезендә башкарыла.»;

д) түбәндәге эчтәлекле $4^{1}$ өлеш өстәргә:

«$4^{1}$. Җирле үзидарә органнары опекага (попечительлеккә) тапшырылган, тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләүне һәм үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләүне билгеләү һәм түләү буенча дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару, әлеге Законга 3 нче кушымтага таянып, Опекага (попечительлеккә) тапшырылган, тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләүне һәм үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләүне билгеләү һәм түләү буенча дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару методикасы нигезендә башкарыла.»;

3) 8 статьяның 1 пунктындагы беренче абзацына «оештыру һәм гамәлгә ашыру» сүзләреннән соң «опекага (попечительлеккә) тапшырылган, тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган

балаларны карап торткан өчен айлык акчалата түләүне һәм үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләүне билгеләү һәм түләү буенча» сүзләрен өстәргә;

4) 9 статьяның 3 өлешендә «оештыру һәм башкару» сүзләреннән соң «опекага (попечительлеккә) тапшырылган, тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап торткан өчен айлык акчалата түләүне һәм үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләүне билгеләү һәм түләү буенча» сүзләрен өстәргә;

5) 1 нче кушымтада:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«Балигъ булмаган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару методикасы»**;

б) беренче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Методика җирле үзидарә органнары тарафыннан балигъ булмаган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару өчен билгеләнә.»;

г) өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

д) 1 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль район, шәһәр округы бюджетына бирелә торган субвенцияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нзі – хезмәт өчен түләүгә акча күчерүләр, процентларда;»;

е) 2 пунктның беренче абзацында «хезмәт хакы» сүзләрен «хезмәт өчен түләү» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 3 пунктта:

беренче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

икенче абзацта «хезмәт хакына» сүзләрен «хезмәт өчен түләүгә» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нзі – хезмәт өчен түләүгә акча күчерүләр, процентларда;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Снз – хезмәт өчен түләүгә акча күчерүләр ставкасы.»;

6) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында
муниципаль берәмлекләрнең җирле
үзидарә органнарына опека һәм
попечительлек өлкәсендә Татарстан
Республикасының аерым дәүләт
вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне оештыру һәм башкару буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару методикасы**

Әлеге Методика җирле үзидарә органнары тарафыннан суд хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип таныган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару өчен билгеләнә.

Муниципаль район, шәһәр округы бюджетына бирелә торган субвенцияләрнең күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$Si = Зi\ ел \times (100\% + Cнзi) \times Ki + Pм,$$

монда:

Si – i-муниципаль берәмлек бюджетына суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яки хокуктан файдалану сәләте чикле дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен башкаруга субвенция күләме;

Зi ел – тиешле елга дәүләт вәкаләтләрен башкарганда i-муниципаль берәмлекнең опека һәм попечительлек буенча белгеч хезмәте өчен түләү чыгымнары (хезмәт өчен түләү төркеменә бәйле рәвештә);

Снзi – хезмәт өчен түләүгә акча күчерүләр ставкасы, процентларда;

Кi – муниципаль берәмлекнең 100 мең өлкән кешесенә бер вазыйфа, әмма Татарстан Республикасының һәр муниципаль районына кимендә бер вазыйфа һәм Татарстан Республикасының һәр шәһәр округына кимендә ике вазыйфа исәбеннән чыгып билгеләнә торган вазыйфалар саны;

Рм – i-муниципаль берәмлекнең опека һәм попечительлек буенча белгечләрне матди тәэмин итү чыгымнары, бу чыгымнар опека һәм попечительлек буенча

белгечләрнең хезмәтенә түләүгә акча түләүләр кертелгән хезмәт өчен түләү чыгымнарының 10 процентына тигез була.»;

7) түбәндәге эчтәлекле 3 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасында
муниципаль берәмлекләрнең җирле
үзидарә органнарына опека һәм
попечительлек өлкәсендә Татарстан
Республикасының аерым дәүләт
вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

**Опекага (попечительлеккә) тапшырылган, тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләүне һәм үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләүне билгеләү һәм түләү буенча дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару методикасы**

Әлеге Методика җирле үзидарә органнары опекага (попечительлеккә) тапшырылган, тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләүне һәм үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләүне билгеләү һәм түләү буенча дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләп чыгару өчен билгеләнә.

1. Муниципаль район, шәһәр округы бюджетына бирелә торган субвенцияләрнең күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$Si=Oci+Oei+Oвi,$$

монда:

Si – i-муниципаль берәмлек бюджетына опекага (попечительлеккә) тапшырылган, тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләүне һәм үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләүне гамәлгә ашыру өчен субвенция күләме;

Oci – i-муниципаль берәмлекнең опекага (попечительлеккә) тапшырылган ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләү чыгымнары;

Oei – i-муниципаль берәмлекнең тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләү чыгымнары;

Овi – i-муниципаль берәмлекнең үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләү чыгымнары.

2. I-муниципаль берәмлекнең опекага (попечительлеккә) тапшырылган ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләү чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Oci = ((P_1 \times K_{1i}) + (P_2 \times K_{2i})) \times 12,$$

монда:

$P_1$ – опекага (попечительлеккә) тапшырылган мәктәпкәчә яшьтәге ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләүнең «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнә торган күләме;

$K_{1i}$ – опекага (попечительлеккә) тапшырылган мәктәпкәчә яшьтәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның мәгариф өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан төгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә планлаштырыла торган еллык уртача саны;

$P_2$ – опекага (попечительлеккә) тапшырылган мәктәп яшендәге ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләүнең «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнә торган күләме;

$K_{2i}$ – опекага (попечительлеккә) тапшырылган мәктәп яшендәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның мәгариф өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан төгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә планлаштырыла торган еллык уртача саны.

3. I-муниципаль берәмлекнең тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләү чыгымнары түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Oei= ((P_1 \times K_{1j}) + (P_2 \times K_{2j}))\times 12,$$

монда:

$P_1$ – тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән мәктәпкәчә яшьтәге ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап тоткан өчен айлык акчалата түләүнең «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль

ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнә торган күләме;

$К_{1j}$ – тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән мәктәпкәчә яшьтәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның мәгариф өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан төгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә планлаштырыла торган еллык уртача саны;

$Р_2$ – тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән мәктәп яшендәге ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны карап торткан өчен айлык акчалата түләүнең «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнә торган күләме;

$К_{2j}$ – тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән мәктәп яшендәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның мәгариф өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан төгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә күрсәтелгән категориядәге балаларның факттагы саны турында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә планлаштырыла торган еллык уртача саны.

4. I-муниципаль берәмлекнең үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләү чыгымнары түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Овi = ((Р \times (К_{1j} + К_{2j} + К_{3j})) + (К_{4j} \times В) + (К_{5j} \times С)) \times (100\ \% + Н) \times 12,$$

монда:

Р – үз йөкләмәләрен түләүле нигездә үтәүче опекуннарга яисә попечительләргә тиешле түләүнең Татарстан Республикасы Гаилә кодексының $141^1$ статьясындагы 1 өлеше нигезендә билгеләнгән күләме;

$К_{1j}$ – тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән мәктәпкәчә яшьтәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның төгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә мәгариф өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан планлаштырыла торган еллык уртача саны;

$К_{2j}$ – тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән мәктәп яшендәге ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның мәгариф өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан төгәлләнгән соңгы ике финанс елында i-муниципаль берәмлектә күрсәтелгән категориядәге балаларның факттагы саны турында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә планлаштырыла торган еллык уртача саны;

$К_{3j}$ – балигъ булмаган гражданнарга хәрби әзерлек үткәрүгә юнәлдерелгән өстәмә белем бирү программалары булган федераль дәүләт мәгариф оешмаларында укый торган, тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның мәгариф өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан төгәлләнгән соңгы ике финанс елында і-муниципаль берәмлектә әлеге категориядәге балаларның факттагы саны турында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә планлаштырыла торган еллык уртача саны;

$К_{4j}$ – тәрбиягә бала алучы гаиләгә бирелгән өч яшькә җитмәгән ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның яки ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә кертелә торган инвалид балаларның йә психик яисә физик үсешендә кимчелекләр булган балаларның, яки девиант холыклы балаларның мәгариф өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан төгәлләнгән соңгы ике финанс елында і-муниципаль берәмлектә күрсәтелгән категориядәге балаларның факттагы саны турында муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә планлаштырыла торган еллык уртача саны;

В – Татарстан Республикасы Гаилә кодексының $141^1$ статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнә торган өстәмә түләү;

$К_{5j}$ – і-муниципаль берәмлектә педагогик яисә медицина белеме булган опекуннарның яисә попечительләрнең мәгариф өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары белешмәләре нигезендә планлаштырыла торган еллык уртача саны;

С – Татарстан Республикасы Гаилә кодексының $141^1$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә билгеләнә торган өстәмә түләү;

Н – хезмәт өчен түләүгә акча күчерүләр ставкасы, процентларда.»

**2 статья**

Әлеге Закон 2019 елның 1 апреленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН *
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 19 март
№ 21-ТРЗ